**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 елның «08» ноябреннән № 262

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары исемлеген алып бару тәртибен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты, «2018 ел йомгаклары буенча халыкның тормыш сыйфатын бәяләү һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеге индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт йөкләмәсен үтәү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 20 апрелендәге 324 номерлы карарының 9 пунктындагы икенче абзацы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан

Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» htt://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетның
2019 елның «08» ноябрендәге № 262
карары белән расланган

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе (алга таба – Тәртип), «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклауны тәэмин итү, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль контроль төрләрен гамәлгә ашыру турындагы мәгълүматларның ачыклыгын һәм үтемлелеген тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарының аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарын һәм муниципаль контроль төрләре исемлеген (алга таба - исемлек) алып бару кагыйдәләрен билгели.

## 2. Исемлекне алып бару.

2.1. Исемлек муниципаль контроль төрләрен һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы»муниципаль берәмлеге территориясендә аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органнарын билгели.

2.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль контроль төрләре һәм җирле үзидарә органнары исемлеге түбәндәге мәгълүматларның системалаштырылган Исемлеге булып тора:

а) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре турында;

б) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль контрольнең тиешле төрләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемнәре турында»;

в) муниципаль контрольнең тиешле төрен җайга салучы Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары реквизитлары турында.

2.3. Исемлекне формалаштыру һәм алып бару Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2.4. Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү, исемлектән мәгълүматларны төшереп калдыру Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән рәсмиләштерелә.

2.5. Исемлекне алып бару кушымта нигезендә, әлеге Тәртипкә беркетелгән форма буенча башкарыла.

2.6. Исемлектәге белешмәләргә үзгәрешләр кертү, я мәгълүматларны исемлектән төшереп калдыру өчен норматив хокукый акт кабул итү нигез булып тора.

2.7. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге 30 көннән дә соңга калмыйча, башкарма комитетының тиешле карарын кабул итү юлы белән 2.6 пунктында күрсәтелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертә.

2.8. Исемлек кәгазь һәм электрон төрләрдә алып барыла. Электрон рәвештә исемлек «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында, расланганнан соң биш көн эчендә урнаштырылырга тиеш.

Үзгәрешләр исемлегенә кертелгән очракта, аның актуаль редакциясе «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында тиешле үзгәрешләр кертелгән көннән биш көн эчендә урнаштырылырга тиеш.

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибенә Кушымта

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төрләре һәм аларны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органнары исемлеген алып бару Тәртибе формасы

| Тәртип № | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «муниципаль берәмлеге территориясендә гамәлгә ашырыла торган муниципаль контроль төре исеме | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль контрольнең тиешле төрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы исеме | муниципаль контрольнең тиешле төрен җайга салучы Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары реквизитлары |
|---|---|---|---|